# Нөнәгәр гомуми урта белем бирү мәктәбенең Кәшифә Тумашева исемендәге мәктәп музее

*Туган илем минем – газиз җирем,*
*Синдә яшәп көн күргән бабам.*
*Музей залларыннан үткән чорның*
*Чынбарлыгын эзлим һәм табам.*






НӨНӨГӘР
УРТА ГОМУМИ
БЕЛЕМ БИРҮ
МӘКТӘБЕНЕҢ
КӘШИФӘ
ТУМАШЕВА
исемендәге
МУЗЕЕ

**Нөнәгәр мәктәбендә музей ачуга хәзерлек эшләре 1998 нче елда башлана. Рәсми рәвештә музей 2005 нче елда ачыла. 2005 нче елда Татарстан Республикасы фән һәм мәгариф министрлыгы, 2013 нче елда Россия Федерациясе фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәп музееен раслаучы таныклыклар бирелә. Музейның гомуми мәйданы - 144 м². Музейда 986 экспонат саклана. Музей өч залны берләштерә.**






# 1 нче зал -“Риваятькә тиң гомер”



Залдагы экспонатлар авылдашыбыз Нөнәгәр авылы кызы татар хатын-кызларыннан беренче булып махсус югары белемгә ия булган режиссер, диктор, педагог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Кәшифә Тумашеваның тормышын һәм иҗатын яктырта.





# Залдан күренешләр










# Залдан күренешләр









# Тумашеваның үз кулы белән язган тәрҗемәи хәле

27/I-55

Автобиография

Тумашевой Кашифы Замалетдиновны.

Родилась в 1902 г. в семье крестьянина-середняка деревни Ревнегар(?), Цивильского р-на ТАССР Замалетдина Шарафутдинова.

Ввиду того, что, как девочка была лишена земельного надела, чтобы избавиться от лишнего „рта" в 1908 году была отдана отцом в люди (родственникам) гр. Рахматуллиным в г. Иркутск, у которых жила до начала 1918 г. Во время нахождения у Рахматуллиных училась в тат. медресе и в „Восточной школе". С 1918 г. жила самостоятельно у родных, в частности у учительницы Сизых, которая мне помогла учиться и экстерно подготовила и дала возможность окончить 9 кл. гимназии в 1920 г.

С восстановлением Советской власти я стала работать артисткой в Татарской труппе при Мусосекции РКП(б) до июля 1920, с июля 1920 по 1921 г. работала артисткой в г. Челябинске, а с 1921–1923 г. артисткой в Тат. драм. труппе при Политпросвете в г. Семипалатинске, с 1923 по 1924 г. работала артисткой в Госуд. Татарском театре в Казани, с 1924 по 1926 г. училась в Татарском театральном техникуме, с 1926 по 1934 г. была оставлена педагогом в театральном техникуме и одновременно работала артисткой, диктором и режиссером в Радиоцентре в Казани, с 1934 по 1939 г. училась в Московском театральном институте. С 1939 по 1953 г. работала режиссером в Тат. Госуд. Академическом театре. Одновременно с 1939 по 1941 г. преподавала в студии при театре, а также с 1943 по 1945 г. была начальником реперткома(?) и с 1945 по 1952 г. преподавала на кафедре мастерства в Каз. театральном училище. И с 1953 г. по настоящее время работаю режиссером в Татгосфилармонии. Репрессированных в семье нет. Член КПСС с 1942 г. в настоящее время являюсь секретарем перв. парторг. ТГФ. Сын Тумашев Р. член КПСС, [illegible]. Сноха преподает в КГУ, дочь аспирантка КГИ(?), зять — Хамматов(?) студент КГУ.

27/I–55 г. Тумашева



**5 яшендә ата-анасы йортыннан аерылып, ерак Өркеттә тутасы гаиләсендә яши башлый. Мәдрәсә, гимназиядә белем ала, татар театр труппасында чыгыш ясый башлый.**
**Кәшифәнең бала-чагы, Өркет шәһәрендә укыган еллары, сәхнәгә атлаган беренче адымнары фотоларда һәм тарихи документларда чагыла.**



**1919-1923 нче еллар... Кәшифә Тумашеваның тормышында Казан чоры аерым урын алып тора. Театр техникумын тәмамлау, татар радиосында беренче диктор булу аның режиссерлыкка булган теләген көчәйтә, ГИТИС ка юл ачыла.**

# Тормыш мизгелләре














**Мәскәүдән кайтуга 1939 нчы елда Кәшифә Тумашеваны татар Академия театрына режиссер итеп билгелиләр. Бу театрда ул 15 елга якын иҗат дәверендә 30 дан артык әсәрне сәхнәләштерә.**



TASSR XKS janьndaqь Sanqat Eşlәre Idarәse.

Qәlәsәqәr Kamal Ismendәge
TATAR ĐӘVLӘT AKADEMIӘ TEATRЬ

Qazan, Zur Galaktionof ur. 13 — Telefon № 30-78, 30-69

1939—40 jьlqь sezon

PROGRAMMA

PREM'JERA — Xәnis Fotrulin

KYZLӘR

drama 4 pәrdәdә 7 kartinada

QATNAŞALAR:

Raisә ........ art. M. Minneaajeva.
art. Z. Başьjrova.
art. F. Xalitof.
Sәlim ........ art. Gl. Urazaki I.
Gadelşa ........ art. Nadrykof.
art. Gl. Xasinof.


Resissjor K. Tumaşeva postanofkasь
Xudoznik M. Sytyşef oformlenise.
Atqazanqan sanqat eşleklese kompozitor S. Sәjdaşef muzьjkasь.

Әdәbi eylek mөdire R. Işmurat.
Resissjor-administrator M. Cansjş.
Spektakine alыp bara resissjor jardәmcese N. Ә. Muzafarof,

Spektakl' kic 8 saqatta başlana.
3 nce zvonoktan son tamaşacьlar zalqa kertelmilәr.
16 jaştan kim bulqan balalar spektakelgә kertelmilәr.

TDAT direktorь X. Alxanof.
Direktor urьnbasarь G. M. Olenel.
Baş administrator V. A. Dundur.

Tatpoligraf, Tat. ASSR ... 1939 r.




**“Күзләр”, ”Хуҗа Насретдин” спектакльләре сәхнәдә зур уңыш белән бара, Кәшифә Тумашева сәләтле, талантлы режиссер буларак танылa.**

# Режиссер спектакльләрнең җырлы булуына игътибар итә. Автор, композитор, рәссам белән тыгыз элемтәдә эшли. Музей экспонатлары шул турыда сөйли.



Сара Садыйкова

"Татарстанның атказанган артисткасы **Сара Садыйкова** ТАССР Министрлар Советы каршындагы сәнгать эшләре идарәсенең 1948 елның 18 март карары нигезендә эштән кыскартылды"...

...Салкын көзгә көндә, көтмәгәндә—уйламаганда, Сара Садыйкова квартирасына Татар дәүләт академия театрының режиссеры **Кәшифә Тумашева** килеп керә. Мәскәү ГИТИСының режиссерлык факультетын тәмамлаган, татар хатын-кызларыннан беренче режиссер Кәшифә ханым Сара Садыйкова белән электән үк яхшы таныш була. Ихтирам белән карый, аның сәхнәдә уйнавын, җырлавын ярата, җае чыккан саен, аңа ярдәм итәргә омтыла.

Бу килүендә ул Сара Садыйковадан М. Фәйзинең "Ак калфак" исемле спектакленә музыка язуын үтенә.

Кәшифә Тумашева








Кәшифә Тумашеваның режиссер буларак иң көчле ягы – артистлар белән эшләү, образларны дөрес итеп гәүдәләндерү, эчке дөньяларын тулы итеп ачуга ирешү.Фотолар шуны раслый.

1955-1962 елларда Спасс башнясында урнашкан Татар дәүләт драма һәм комедия театрында баш режиссер булып эшли.



**Театр коллективы туктаусыз юлда, халыкка – хезмәттә булуын раслаучы фотолар һәм документлар сакланып калган.**





**Коллектив Урта Азиядә**





ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!

РОССИЙСКАЯ СОВЕТСКАЯ ФЕДЕРАТИВНАЯ СОЦИАЛИСТИЧЕСКАЯ РЕСПУБЛИКА

# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

Указом Президиума Верховного Совета РСФСР от 15 июня 1957 г.

Тов. ТУМАШЕВА Кашифа Замалетдиновна

За заслуги в области советского искусства и литературы и в связи с декадой татарского искусства и литературы в гор. Москве

награждена Почетной Грамотой Президиума Верховного Совета РСФСР.

Председатель Президиума Верховного Совета РСФСР (М. Тарасов)

Секретарь Президиума Верховного Совета РСФСР (П. Зимин)



ТАТАРСТАН АССР

ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ

Иптәш Тумашева Кәшифә Җәмаләтдин кызы

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Верховный Советы Президиумы татар совет сәнгатен үстерүдәге хезмәтләрегез өчен

СЕЗГӘ ТАТАРСТАН АССР ның

# СӨНГАТЬ АТКАЗАНГАН ЭШЛЕКЛЕСЕ

ИСЕМЕН БИРДЕ

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе (С. Низамов)

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре (А. Пятакова)

№ 784

КАЗАН, КРЕМЛЬ. 16 февраля 1957 ел.

Танылган режиссер, республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты театр сәхнәсе әһелләре гаиләсендә туган Равил абый әнисе юлын сайлый- гомерен сәхнә белән бәйли.





Тумашев Равил Рәхим улы

п



**1923 елда ире Рәхим абый биргән аяк киеме - музейда кадерле экспонат**

**Эш өстәле һәм андагы әйберләр Кәшифә апаның тормышы, сәхнә эшчәнлеге турында сөйли**





# 2 нче зал - «Туган як»

Бу бүлектә туган як тарихы, авылның үткәне, ата-бабаларыбызның тормыш-көнкүреше турында архивлардан алынган тарихи мәгълүматлар бирелгән. Эш кораллары, савыт-сабалар, кул эшләре, киемнәр күрсәтелгән.



## Өйнең түр ягы авылыбыз осталарының кул эшләре белән бизәлгән.



# Биредәге экспонатлар авыл халкының оста һөнәр ияләре булуын раслый .










Моннан 110-115 ел элек тегелгән күлмәк һәм пальто тегүченең осталыгын күрсәтүче экспонатлар. Бу төбәктә яшәгән борынгы халык киемнәре дә музейда саклана.







**Юкка чыгып баручы авыллар тарихын да барлыйбыз. Тәрхән авылын республикада түгел, хәтта, районда да белмәүчеләр күп. 23- 25 хуҗалыктан торган бу авылдан бик күп хезмәт алдынгылары һәм галимнәр чыкты. Стенд авыл тарихын сөйли.**



# 3 нче зал – “Авылыбызның хәрби һәм хезмәт даны”



# Биредә туган колхоз, мәктәп тарихы, Бөек ватан сугышында катнашкан һәм сугышчан-интернационалист якташларыбыз истәлеге тупланган.






# Стендтагы документлар бабаларыбызның батырлыгы турында сөйли.



# 100 елдан артык тарихы булган мәктәпнең укучылары, укытучылары, уңышлары турында фотолар, архив материаллары сөйли.






# Партия һәм совет работниклары, танылган якташларыбыз хакында материаллар урын алган.






# Музей тормышыннан күренешләр









# Укучылар экскурсия үткәрәләр









# Музейдан кеше өзелми…









# “Риваятькә тиң гомер” кичәсеннән күренешләр



# “Риваятькә тиң гомер” кичәсеннән күренешләр










# Тумашева турында сәхнәдәшләренең истәлекләре тупланган “Мирас” җыентыгы



# Тумашева турында сәхнәдәшләре…

*“Она была первой на татарской сцене женщиной-режиссером, Кашифа Замалетдиновна Тумашева. Впрочем, многие помнят её ещё и актрисой, но и тогда она не скрывала своей мечты – посвятить себя поприщу, которое всегда считалось привилегией мужчин, стать полновластной хозяйкой сцены.»*



***Рәшидә Җиһаншина***

# Тумашева турында сәхнәдәшләре…



**Мөхәммәт Хәмзин**

*“1955 нче елда Кәшифә Тумашеваны безгә баш режиссер итеп билгеләделәр. Менә ул килгәч, театрыбыз башкачарак эшли башлады. Иҗат коллективына җан керде, нәтиҗәле эш башланды. Безнең театр коллективына Кәшифә апа Тумашева шикелле энергияле режиссер-педагог, сабырлык белән иҗат коллективын тәрбияли белә торган режиссер кирәк булган икән.”*

***Музейда туган хисләр…***



**Зыятдинов Азат Шәймуллович**


17.10.2016.

Нөнәгәр авылының Кашифә Тумашева [и]мендәге музее белән танышу бәхе[те]нә ирештем. „Бәхетенә ирештем"-дип [яз]ам, чөнки бу авыл мәктәбенә үз те[ла]гем белән, балалар белән очрашуга [ки]лгән идем. Чөнки, хәйран гына үзен[чә]лекле, тормыш юлы узган кеше мин [б]алаларга шул турыда сөйләдем һәм [кы]зыклы гына очрашу булды бу. [Ә]валеы да кызыклы булды. Данил [ага]ның музей белән таныштыруга [ч]акырды, рәхмәт төшкере. Бу музейда [к]үңелемә якын булган шәхесләр [и]смы белән танышу бәхетенә [и]рештем, шикә алып куандым. Музей шул кадерле истәлекләрне кадерләп саклый, киләчәкләргә тәфсилләти ац-ата. Үткәндәге гыйрәтле шәхес[лә]рнең, шәхесләрнең, шул заманның [үз]енчәлекләрен безгә - киләчәкләргә [д]ә җиткерә. Мең рәхмәтләр, шушы [м]узей казанышларыбызны бүгенге [б]уыннарга җиткерүчеләргә. Бәхет [б]улыгыз.

/Азат Зыятдинов/
профессор, Түбән Кама
шәһәренең шәрәфле
гражданины
Тузар авыл егете.




**Минкусов Иван Егорович**



14/IX 2013 Кадерле туганнар!
Якташлар. Сезнең музейда
булдым. Рәхмәт сезгә,
онытылмагансыз үзебезнең
якташларыбыз эшләгәннәрен
эзләрен. Бу музей яшьләргә
бик күп файдалы аларга
була! Уңышлар телим сезгә
кемнең исәнлек-саулык
озак гомер
Рәхмәт сезгә бик зур
Профессор КГМА из Казани
Иван Егорович Минкусов



**Альберт һәм Лира Гыйләҗевлар**



Нәнәгәр авылы мәктәбе
каршында әчтәлекле, бай һәм
матур музей ачылуга бик чын
күңелдән шатландык!
Музей бит ул авыл халкы
кешеләре — бабалар эзе, киләсе
буынга зур хатирә - истәлек.
Бөтен көчен, белемен музейны
оештыручы Дания ханымга
зур рәхмәтебезне белдерәбез!
Казаннан Гыйләҗевләр
гаиләсе
31.01.2009 ел. Лира һәм Альберт

Нөнәгәр урта мәктәбенең
100 еллыгына мәртәбәле кунак
булып килүем минем әнием
Гыйлминаз Фәретдин кызы Их-
санова исеме белән бәйле.
Әнием 1917-18 елларда Һал-
мыкта рус-татар мәктәбен
тәмамлап Нөнәгәргә мәктәп
ачарга (советча) җибәрелә. Әнием
күңелендә авыл халкының бик
ягымлы, әйбәт булып, яшь укыту-
чыга ярдәм итүләре якты истә-
лек булып калган иде, безгә еш
кына сөйли иде.
Әниебез Гыйлем(ана) - олысы
кечесе аны шулай дип йөртә-
ләр иде, Нөнәгәрдә озак эшли ал-
мый, Һалмыктагы бер рус шу[illegible]
сенең „игътибары"ннан баш тарт-
кач, аны Киров өлкәсенең Кара
урман ягындагы Ямыя авылына
(Вятские Поляны р-ны) җибәрәләр,
анда да мәктәп ача, 20 елда [illegible]
[illegible] авылы мулласы малае [illegible]
гә кияүгә чыга.
Без дүрт бала үсеп, өчә-
ебез орденлы укытучылар, бер ишә
шә озак еллар ялга чыктылар.




**Венера һәм Ләбибә Ихсановалар**

Нөнәгәр мәктәбе миңа укыту-
чыларының белемле, туры
булулары, балаларының белемле
булулары белән [illegible] отадыр.
Ул минем өчен бер могҗиза.
Һәр кешегә аерым ихтирам күр-
сәтелеп, зурлап күрсәтелгән.
Мәктәпкә ярдәм итеп, аны бү-
генге югарылыкка күтәргән
җитәкчеләргә, мәктәп директорының
укытучыларга аерым рәхмәт.

Венера Ихсанова
„Азат хатын" журна-
лының баш редакторы,
Ләбибә Ихсанова
балалар язучысы;
31 гыйнвар, 2009 ел.



**Йосыпова Нурфия**




Татар халкы һәрвакыт фида-
карьләренең тырышлыгы белән яшә-
гән алга барган. Бу мирасны ачыкла-
ру, аны җилләтеп җиткерү дә фида-
карь хезмәт таләп итә. Дания
апаның фидакарь хезмәте алдында
баш иям. Мирасга озын гомер, авыл-
да, тарихта мардай кешеләр булып
торуын телим

Нурфия Йосыпова (Гарифулл-
ина)
филология фәннәре канди-
даты, КФУ доценты.



**Гыйльфанова Рәзинә**



Мәктәп каршында оештырыл-
ган Җәмилә Туманева исемен-
дәге музейда мин беренче генә
тапкыр түгел. Һәр килүем са-
ен үзем өчен яңалык алып рухи д[а]
баеп китәм. Музейга мин
укучылар б/н килдем. Данис
апаның күп мәгълүматлы
чыгышы минем дөнья-
ямне тагын да киңәйтүгә
ит, өстәп мәгълүматлар
б/н баета. Рәхмәт аңа, шу-
ның өчен!

20.03.09.

Татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Гыйльфанова



# Музей җитәкчесе-

# Кәлимуллина Дания Закирҗан кызы

*Халитовлар гаиләсе һәм мәктәп җитәкчеләре белән*



*Зөмәррә Халитова-Тумашева музейда*



# *Сезне музеебызда көтеп калабыз.*
# *Рәхим итегез!*

***Безнең адрес**: Балтач районы, Нөнәгәр авылы*
*Мәктәп урамы, 89 нчы йорт*
***Телефонннар:** 8 (84368) 3-85-14, 8 (84368) 3-85-31, 89172926558*
***E-mail:** dania.4519@mail.ru, nuriner@yandex.ru*